ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**“31” октябрь 2019 ел** **№ 835**

**2019-2025 елларга Арча муниципаль районының авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча адреслы муниципаль программаны раслау турында**

«Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү Фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль законны, Арча районы прокуратурасының гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү өлкәсендәге законнарны бозуларны бетерү турында 2019 елның 14 октябрендәге 02-08-04/210-2019 номерлы күрсәтмәсен үтәү йөзеннән һәм гражданнарның имин һәм уңайлы яшәү шартларын булдыру максатларында, Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР бирә:

1. 2019-2025 елларга Арча муниципаль районының авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программаны расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты аппаратының инфраструктура үсеше бүлеге җитәкчесе Р.В. Хәбибуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Ә.Галимуллин

Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
2019 елның 31 октябрь
835 номерлы карары
белән расланган

**2019-2025 елларга Арча муниципаль районының авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча адреслы муниципаль программа**

**Программаның паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2019-2025 елларга Арча муниципаль районының авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча адреслы муниципаль программа (алга таба – Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигезләр | " Яшәүгә яраксыз торак фондын тотрыклы кыскартуны тәэмин итү" федераль проектын тормышка ашыру, «Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү Фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон |
| Муниципаль заказчы – Программаның координаторы | Татарстан Республикасы “Арча муниципаль районы” муниципаль берәмлеге |
| Программаны төп эшләүче | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты |
| Программаның төп максатлары | Азкатлы торак төзелешен үстерү кирәклеген исәпкә алып, җирле үзидарә органы торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыру Фонды акчалары исәбеннән финанс ярдәме күрсәтүнең федераль закон белән билгеләнгән шартларын үтәүне тәэмин иткәндә, авария хәлендә дип танылган һәм биналарның милекчеләре гражданнарны күчерү буенча төбәк программасында катнашырга әзер булган авария хәлендәге күпфатирлы йортлардан гражданнарны күчерүне финанс һәм оештыру ягыннан тәэмин итү |
| Программаны төп бурычлары | Авария хәлендә дип танылган торак фондыннан гражданнарны күчерү;<br>авария хәлендә дип табылган һәм эксплуатацияләү барышында физик тузу сәбәпле сүтелергә тиешле дип танылган күпфатирлы йортларны сүтү;<br>авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү өчен шартлар тудыру |

| | |
|---|---|
| Программаны тормышка ашыру вакыты | 2019 - 2025 еллар, шул исәптән:<br>2024 ел этабы – 2025 елның 1 сентябренә кадәр. |
| Программаның төп чараларын башкаручылар | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты |
| Программаны финанслау чыганаклары һәм күләмнәре | Программаны финанслау Дәүләт корпорациясе – торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итүче Фонд (алга таба – Фонд) һәм Татарстан Республикасы бюджеты хисабына тормышка ашырыла:<br>Программаны финанслауның гомуми күләме-1545600 сум, шул исәптән:<br>- РФ бюджеты-1298149,44 сум;<br>- ТР бюджеты – 247450,56 сум. |
| Программаны үтәүнең планлаштырылган күрсәткечләре | Программа үтәлешенең төп күрсәткечләре Программаның 1нче һәм 5нче кушымталарында китерелгән |

## Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа методлары белән хәл итү кирәклеген нигезләү

Татарстан Республикасында дәүләт торак сәясәтенең гражданнар өчен һәркем ала алырлык торак белән, анда имин һәм уңайлы яшәү шартларын тәэмин итә торган, торак өлкәсенең тотрыклы эшләвенә һәм үсешенә күчү проблемасын комплекслы хәл итүгә юнәлдерелгән бурычларының берсе булып авария хәлендәге торак фондында яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшыртуга булган хокукын гамәлгә ашыруны тәэмин итү тора.

Әлеге Программада авария хәлендәге торак фонды дигәндә, 2017 елның 1 гыйнварына кадәр билгеләнгән тәртиптә файдалану барышында физик яктан тузу сәбәпле авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип танылган күпфатирлы йортларда торак биналар җыелмасы аңлашыла.

Арча муниципаль районында 2017 елның 1 гыйнварына күчерү мәйданы 28 кв.метр тәшкил иткән 1 кеше яши торган 1 КФЙ авария хәлендә дип табылган. Әлеге бина муниципаль милектә тора.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан Фондның «ТКХ реформасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасына авария хәлендәге торак фондының саны турында белешмәләр кертү юлы белән, авария хәлендәге торак фонды турында белешмәләрнең дөреслеген тәэмин итү өчен, чаралар күрелә. Күрсәтелгән белешмәләр КФЙны авария хәлендә һәм яшәү өчен яраксыз дип тану турындагы карарларның, тикшерү актлары, бәяләмәләрнең скан-күчермәләре, шулай ук фотоматериаллар белән раслана.

Авария хәлендәге торак фондында яшәүче гражданнарның күбесе хәзерге вакытта билгеләнгән таләпләргә туры килә торган торакны мөстәкыйль рәвештә сатып ала алмый.

Авария хәлендәге торак фондында яшәүче гражданнарны торак белән тәэмин итү проблемасын хәл итүгә күрсәтелгән гражданнарны күчерү өчен муниципаль берәмлек бюджетында җитәрлек акчалар булмау каршылык тудыра.

Проблема, әлеге Программаны тормышка ашыру кысаларында, авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерүгә Дәүләт корпорациясе – торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итүче Фонд (алга таба – Фонд) һәм Татарстан Республикасы бюджеты хисабына тиешле финанс ярдәме күрсәткәндә, хәл ителергә мөмкин.

## II. Программаның төп максатлары, бурычлары һәм тормышка ашыру вакыты

Программаның төп максатлары булып азкатлы торак төзелешен үстерү кирәклеген исәпкә алып, җирле үзидарә органы торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыру Фонды акчалары исәбеннән финанс ярдәме күрсәтүнең федераль закон белән билгеләнгән шартларын үтәүне тәэмин иткәндә, авария хәлендә дип танылган һәм биналарның милекчеләре гражданнарны күчерү буенча төбәк программасында катнашырга әзер булган авария хәлендәге күпфатирлы йортлардан гражданнарны күчерүне финанс һәм оештыру ягыннан тәэмин итү тора.

Билгеләнгән тәртиптә авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле дип танылган күпфатирлы йортларның исемлеге программаның 2 нче кушымтасында китерелгән.

Программа 2024-2025 елларда тормышка ашырылачак.

## III. Программаның чаралары

Гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү торак законнары нигезендә, «Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү Фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон кысаларында гражданнарга торак урыны бирү юлы белән башкарыла, ул торак пункт чикләрендә яшәү урыны буенча булырга мөмкин.

Гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү өчен Арча муниципаль берәмлегенә, билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 2 өлешенең 2 һәм 3 пунктларында күрсәтелгән шартларга туры килә торган йортлар төзүне яки мондый йортларны төзүчеләрдән торак биналар сатып алуны тәэмин итәргә кирәк.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Арча муниципаль районы башкарма комитеты дәрәҗәсендә «Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү Фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясында каралган Фонд чаралары хисабына финанс ярдәме күрсәтү шартларын үтәүне тәэмин итәргә кирәк.

## IV. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча чараларны гамәлгә ашыру өчен финанс чаралары Фонд һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән формалаштырыла. Программаны гамәлгә ашыруга гомуми чыгымнар барлык финанслау чыганаклары хисабына 1545600сум тәшкил итәчәк.

Программаны финанслау чаралары күләме Программага кертелгән, алардан файдалану барышында физик яктан тузу сәбәпле авария хәлендә дип һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип танылган күпфатирлы йортлар исемлеге, гражданнарга бирелә торган торак биналарның бер квадрат метр гомуми мәйданының планлаштырыла торган бәясе күләме һәм гражданнар (юридик затлар) милкендәге тузган торак биналарның гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен планлаштырыла торган сатып алу бәясе күләме, шулай ук авария хәлендәге күпфатирлы йортларда гражданнарны Программаның 3 нче номерлы кушымтасы буенча күчерү ысуллары нигезендә билгеләнә.

2019-2025 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерүгә финанс ярдәме чараларын бүлү Программаның 4 нче номерлы кушымтасында бирелгән.

Бер квадрат метрның сатып алу бәясе муниципаль берәмлекләрдә бәяләү экспертизалары нигезендә билгеләнә.

Программаны гамәлгә ашырганда, сатып алу бәясе муниципаль берәмлек белән авария хәлендәге торак милекчесе арасында төзелә торган килешү нигезендә, яисә милекченең программа шартлары белән килешмәве очрагында, муниципаль ихтыяҗлар өчен мөлкәтне суд тәртибендә тартып алган очракта үзгәртелергә мөмкин.

Казан шәһәрендә авария хәлендәге торак фонды торак биналарның милекчеләренә башка уңайлыклары булган торак урыннары бирү буенча судлашу тәҗрибәсен исәпкә алып, шулай ук Казан шәһәрендәге милекчеләрдән авария хәлендәге торак сатып алу бәясенең югары булуын исәпкә алып, бюджет акчаларын экономияләү максатыннан, Казан шәһәре буенча авария хәлендәге торак

милекчеләренә алмашу килешүләре буенча төзекләндерелгән торак бирү турында Карар кабул ителде.

Программа нигезендә гражданнарга бирелә торган торакның гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен планлаштырыла торган бәя күләме 2024 ел этабы буенча 46,0 мең сум тәшкил итә.

Әлеге бәя алдан кабул ителде һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен биналар сатып алуга электрон аукцион нәтиҗәләре буенча үзгәрергә мөмкин.

Торак биналар, Россия Федерациясе Торак кодексының 89 статьясы нигезендә, барлык муниципаль берәмлекләрдә авария хәлендәге торак фондының торагын яллаучыларга бирелә.

Сатып алына торган торака карата таләпләр Программаның 6нчы номерлы кушымтасында бирелгән.

Фонд акчалары хисабына алынган җирле бюджет акчалары, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары бары тик түбәндәгеләргә тотыла:

- йорт төзүчеләрдән күпфатирлы йортларда (шул исәптән төзелеп бетмәгән күпфатирлы йортларда, гражданнарның һәм (яки) юридик затларның акчаларын җәлеп итү белән төзелә торган (булдырыла торган) күпфатирлы йортларны да кертеп) яки Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында (алга таба – блоклап төзелгән йортлар) күрсәтелгән йортларда торак алу, һәм (яки) мондый йортларны төзүгә;

185-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә, авария хәлендәге торак фондына керә торган торагы булган затларга түләү, Россия Федерациясе Торак кодексының 32 нче маддәсе нигезендә, тартып алынган торак өчен түләү;

185-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә, әлеге торак урнашкан йортларны төзүче булмаган затлардан авария хәлендәге торак фондыннан күчерүче гражданнарга бирү өчен, торак сатып алуга.

Программаны үтәүнең этаплар буенча планлаштырылган күрсәткечләре Программаның 5нче номерлы кушымтасында бирелгән.

## V. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Дәүләт заказчысы, Программа чараларын өлешләп финанслауны тәэмин итү өчен, Фондка гаризалар тапшыра, авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча чараларны гамәлгә ашыруның барышын контрольдә тота.

Программаны башкаручы-Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты-Программа чараларын тормышка ашыру, аларның ахыргы нәтиҗәләре, бүлеп бирелә торган финанс чараларыннан максатчан файдалану өчен җаваплы һәм:

гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү муниципаль программаны эшләү һәм раслауны;

“Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү Фонды турында” 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 5-9.1 һәм 12 пунктларында каралган Фонд акчалары исәбеннән финанс ярдәме күрсәтү шартларын үтәүне;

- муниципаль берәмлек территориясендә авария хәлендәге торак фондына инвентаризация үткәрүне һәм алга таба күзәтеп торуны;

- гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерүгә юнәлдерелгән акчаларны тоту турындагы хисапны алып баруны һәм аны Программаның дәүләт заказчысына тапшыруны;

- авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерүгә юнәлдерелгән бюджет акчаларын куллануны контрольдә тотуны тәэмин итә.

## VI. Программа белән идарә итүне оештыру, аны тормышка ашыруны тикшереп тору һәм нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаның дәүләт заказчысы Программаны гамәлгә ашыру барышына гомуми җитәкчелек итә һәм контрольдә тота, билгеләнгән вакытта Программаны тормышка ашыру барышы һәм Фондның финанс чараларын тоту турында Фондка хисап тапшыра.

Хисапны формалаштыру максатларында, Программаның дәүләт заказчысы Программаны тормышка ашыруның барышы турында кирәкле хисап мәгълүматларын Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетыннан алуны тәэмин итә.

2019-2025 елларга Арча муниципаль
районының авария хәлендәге торак фондыннан
гражданнарны күчерү буенча
адреслы муниципаль программага
1 нче кушымта

## 2019-2025 елларга Арча муниципаль районының авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча адреслы муниципаль программаның төп чаралары нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары

| Программаны үтәү күрсәткечләре | Үлчәү берәмлеге | Программаны үтәүдә ирешелгән нәтиҗә |
|---|---|---|
| 2019 – 2025 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча муниципаль адреслы программаны үтәү нәтиҗәсендә күченгән халык саны (алга таба – Программа) | кеше | 1 |
| Программага кертелгән авария хәлендәге күпфатирлы йортларда теркәлгән халыкның гомуми санынннан Программаны үтәү кысаларында күчерелгән халык өлеше | процент | 100 |
| Программаны үтәү кысаларында әлеге йортларда яшәүчеләр күчерелгән авария хәлендә дип танылган күпфатирлы йортлар саны | данә | 1 |
| Программаны үтәү кысаларында әлеге йортларда яшәүчеләр күчерелгән авария хәлендәге күпфатирлы йортлар өлеше | процент | 100 |
| Программаны тормышка ашыру кысаларында торак һәм торак булмаган бүлмәләр буенча азат ителгән бүлмәләрнең гомуми саны (яллау, сатып алу буенча суммада һәм алмашу буенча берәмлекләрдә һәм квадрат метрларда) | данә | 28 кв.м гомуми мәйданлы 1торак |
| Программаны үтәү кысаларында күчерелгән авария хәлендәге барлык күпфатирлы йортларга карата, алардан файдалану барышында физик яктан тузу сәбәпле, 2017 елның 1 гыйнварына кадәр авария хәлендә дип танылган һәм сүтелергә тиешле авария хәлендәге күпфатирлы йортларның өлеше | процент | 100 |
| Программаны үтәү өчен Татарстан Республикасына карата Дәүләт корпорациясе - Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү Фонды акчалары чик нормасыннан тотылган акчалар өлеше | процент | 100 |

Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
2019 елның ________________
____ номерлы карары
белән расланган

**2019-2025 елларга Арча муниципаль районының авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча адреслы муниципаль программа**

**Программаның паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2019-2025 елларга Арча муниципаль районының авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча адреслы муниципаль программа (алга таба – Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигезләр | " Яшәүгә яраксыз торак фондын тотрыклы кыскартуны тәэмин итү" федераль проектын тормышка ашыру, «Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү Фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон |
| Муниципаль заказчы – Программаның координаторы | Татарстан Республикасы “Арча муниципаль районы” муниципаль берәмлеге |
| Программаны төп эшләүче | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты |
| Программаның төп максатлары | Азкатлы торак төзелешен үстерү кирәклеген исәпкә алып, җирле үзидарә органы торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыру Фонды акчалары исәбеннән финанс ярдәме күрсәтүнең федераль закон белән билгеләнгән шартларын үтәүне тәэмин иткәндә, авария хәлендә дип танылган һәм биналарның милекчеләре гражданнарны күчерү буенча төбәк программасында катнашырга әзер булган авария хәлендәге күпфатирлы йортлардан гражданнарны күчерүне финанс һәм оештыру ягыннан тәэмин итү |
| Программаны төп бурычлары | Авария хәлендә дип танылган торак фондыннан гражданнарны күчерү;<br>авария хәлендә дип табылган һәм эксплуатацияләү барышында физик тузу сәбәпле сүтелергә тиешле дип танылган күпфатирлы йортларны сүтү;<br>авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү өчен шартлар тудыру |

2019 - 2025 елларга Арча муниципаль районының авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программага 2 нче кушымта
"

2017 елның 1 гыйнварына кадәр авария хәлендә дип танылган күпфатирлы йортлар исемлеге

| № т/б | Торак пунктның исеме | Күпфатирлы йортның адресы | Йортны файдалануга тапшыру елы | Күпфатирлы йортны авария хәлендә дип тану датасы | Авария хәлендәге торак фонды турында белешмәләр 2025 елның 1 сентябренә кадәр | | Күчерүнең планлаштырылган вакыты |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Мәйдан, кв. метр | кеше саны | |
| 2019-2025 елларга Арча муниципаль районының авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча адреслы муниципаль программа буенча, аның кысаларында дәүләт корпорациясе – торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм Фонды акчалары исәбеннән, шул исәптән: | | | x | x | 28,00 | 1 | x |
| 1. | Чүриле тимер юл разъезды бистәсе | Чүриле тимер юл разъезды п., Станция ур., 1 йорт | 1931 | 12.08.2014 | 28,00 | 1 | 31.08.2025 |

2019 - 2025 елларга Арча муниципаль районының авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программага 3 нче кушымта

Күчерү ысулы буенча 2017 елның 1 гыйнварына кадәр авария хәлендә дип танылган торак фондыннан гражданнарны күчерү чараларын гамәлгә ашыру планы,

| № т/б | Ммуниципаль берәмлек исеме | Барлыгы күчерелә торган торак урыннар мәйданы, кв. метр | Программа кысаларында торак биналар сатып алу белән бәйле булмаган һәм бюджет акчаларын кулланмыйча торак сатып алу белән бәйле рәвештә күчерү | | | | | Бюджет акчалары хисабына торак биналар сатып алуга бәйле программа кысаларында күчерү | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | барлыгы | шул исәптән | | | | барлыгы | | | шул исәптән | | | | | | | |
| | | | | милекчеләрдән торак биналар сатып алу | | төзелгән территорияне үстерү турында | ирекле торак фондына күчү | | | | йортлар төзелеше | | төзүчеләрдән торак биналар сатып алу, шул исәптән: | | | | төзүче булмаган затлардан торак биналар сатып алу | |
| | | | | | | | | | | | | | төзелә торган йортларда | | файдалануга тапшырылган йортларда | | | |
| | | | күчерелә торган мәйдан, кв. | күчерелә торган мәйдан, кв. | бәя, сум | күчерелә торган мәйдан, кв. метр | бәя, сум | күчерелә торган мәйдан, кв. метр | сатып алына торган мәйдан, кв. метр | бәя, сум | сатып алына торган мәйдан, кв. метр | бәя, сум | сатып алына торган мәйдан, кв. метр | бәя, сум | сатып алына торган мәйдан, кв. метр | бәя, сум | сатып алына торган мәйдан, кв. метр | бәя, сум |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
| | 2019 – 2025 елларга Арча муниципаль районының авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программа кысаларында дәүләт корпорациясе – торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм Фонды акчалары исәбеннән каралган финанслауның барлыгы, шул исәптән: | 28,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 28,00 | 33,60 | 1 545 600,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 33,60 | 1 545 600,00 | 0,00 | 0,00 |
| | Барлыгы 2024 ел этабы буенча | 28,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 28,00 | 33,60 | 1 545 600,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 33,60 | 1 545 600,00 | 0,00 | 0,00 |
| 1. | Арча муниципаль районы | 28,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 28,00 | 33,60 | 1 545 600,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 33,60 | 1 545 600,00 | 0,00 | 0,00 |

2019 - 2025 елларга Арча муниципаль районының авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программага 4 нче кушымта

## 2017 елның 1 гыйнварына кадәр авария хәлендәге дип танылган торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча чаралар планы

| № т/б | Муниципаль берәмлек исеме | Күчерүгә планлаштырылган халык саны, кеше | Күчерелә торган торак урыннар саны | | | Торак биналарның күчерелә торган мәйданы | | | Программаны финанслау чыганаклары | | | | Белешмә: бюджет акчаларын экономияләү буенча исәп-хисап суммасы | | | Белешмә: торак урыннар бәясенең бер өлешен каплау | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | барлыгы, берәмлек | шул исәптән | | барлыгы, кв. метр | шул исәптән | | барлыгы, сум | шул исәптән | | | барлыгы, сум | шул исәптән | | барлыгы, сум | шул исәптән | |
| | | | | гражданнарның милке, берәмлек | муниципаль милек, берәмлек | | гражданнарның милке, кв. метр | муниципаль милек, кв. метр | | Фонд исәбеннән, сум | Россия Федерациясе субъекты бюджеты исәбеннән, сум | җирле бюджет исәбеннән, сум | | гражданнарны төзү территориясен үстерү турындагы килешү буенча күчерү хисабына, сум | гражданнарны ирекле муниципаль торак фондына күчерү хисабына, сум | | торак биналарның милекчеләре хисабына, сум | башка затлар (ДРЗТ буенча инвестор) хисабына, сум |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
| | 2019-2025 елларга Арча муниципаль районының авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программа кысаларында дәүләт корпорациясе – торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм Фонды акчалары исәбеннән каралган финанслауның барлыгы, шул исәптән: | 1 | 1 | 0 | 1 | 28,00 | 0,00 | 28,00 | 1 545 600,00 | 1 298 149,44 | 247 450,56 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| | Барлыгы 2024 ел этабы буенча | 1 | 1 | 0 | 1 | 28,00 | 0,00 | 28,00 | 1 545 600,00 | 1 298 149,44 | 247 450,56 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 1. | Арча муниципаль районы | 1 | 1 | 0 | 1 | 28,00 | 0,00 | 28,00 | 1 545 600,00 | 1 298 149,44 | 247 450,56 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |

2019 - 2025 елларга Арча муниципаль районының авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программага 5 нче кушымта

## 2017 елның 1 гыйнварына кадәр авария хәлендә дип танылган торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча планлаштырылган күрсәткечләр

| № т/б | Муниципаль берәмлек исеме | Күчерелә торган мәйдан, кв. метр | | | | | | | | Күчүче кешеләр саны, кеше | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | барлыгы | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | барлыгы |
| | 2019 – 2025 елларга Арча муниципаль районының авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программа кысаларында дәүләт корпорациясе – торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм Фонды акчалары исәбеннән финанслауның барлыгы, шул исәптән: | х | х | х | х | х | 4,20 | 23,80 | 28,00 | х | х | х | х | х | 0 | 1 | 1 |
| | Барлыгы 2024 ел этабы буенча | х | х | х | х | х | 4,20 | 23,80 | 28,00 | х | х | х | х | х | 0 | 1 | 1 |
| 1. | Арча муниципаль районы | х | х | х | х | ha | 4,20 | 23,80 | 28,00 | х | х | х | х | х | 0 | 1 | 1 |

2019-2025 елларга Арча муниципаль
районының авария хәлендәге торак фондыннан
гражданнарны күчерү буенча
адреслы муниципаль программага
6 нчы кушымта

# Авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү программасы кысаларында төзелә торган яисә сатып алына торган торакка карата тәкъдим ителгән таләпләр

Файдалануга тапшырылган йортларда йорт төзүче булмаган затлардан торак сатып алуга контрактлардан һәм милекчеләрдән торак сатып алуга контрактлардан тыш, гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча төбәк адреслы программаларны гамәлгә ашыру максатларында сатып алулар үткәрүгә документлар әзерләгәндә, дәүләт (муниципаль) заказчыларга әлеге таләпләрне исәпкә алырга тәкъдим ителә.

Файдалануга тапшырылган йортларда йорт төзүче булмаган затлардан торак сатып алуга контрактлар буенча сатып алына торган торакка карата таләпләр дәүләт (муниципаль) заказчысы тарафыннан мөстәкыйль рәвештә билгеләнә.

| № т/б | Таләпнең атамасы | Таләпнең эчтәлеге |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Йортның проект документларына карата таләпләр | Проект документларында параметрларның проект күрсәткечләре һәм торакның башка проект характеристикалары, шулай ук аның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча планлаштырыла торган чаралар, аны төзегәндә һәм файдаланганда гражданнарның гомере һәм сәламәтлеге өчен (инвалидларны һәм мөмкинлекләре чикләнгән затларның башка төркемнәрен дә кертеп), физик һәм юридик затлар милке, дәүләт яки муниципаль милек, әйләнә-тирә мохит өчен куркынычсыз булырлык итеп урнаштырылган булырга тиеш.<br>Проект документлары түбәндәге таләпләр нигезендә эшләнә:<br>- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 16 февралендәге 87 нче номерлы «Проект документлары бүлекләре составы һәм аларны эчтәлегенә карата таләпләр турында» карары;<br>2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент" Федераль законы;<br>2009 елның 30 декабрендәге 384-ФЗ номерлы |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | «Биналарның һәм корылмаларның иминлеге турында техник регламент” Федераль законы;<br>- СП 42.13330.2016 «Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү»;<br>- СП 54.13330.2016 «Күпфатирлы торак бинлар»;<br>- СП 59.13330.2016 «Халыкның хәрәкәтләнүе чикле төркемнәре өчен биналарның һәм корылмаларның файдалана алырлык булуы»;<br>- СП 14.13330.2014 «Сейсмик районнарда төзелеш»;<br>- СП 22.13330.2016 «Биналар һәм корылмаларның нигезләре»;<br>- СП 2.13130.2012 «Янгыннан саклау системалары. Объектларның янгынга каршы торучанлыгын тәэмин итү»;<br>- СП 4.13130.2013 «Янгыннан саклау системалары. Объектларда янгын таралуны чикләү. Күләмле-планлаштырылган һәм конструктив карарларга карата таләпләр»;<br>- СП 255.1325800 ”Биналар һәм корылмалар. Файдалану кагыйдәләре. Гомуми нигезләмәләр”. Проект документларын рәсмиләштерү «Проект һәм эш документларына төп таләпләр» ГОСТ Р 21.11.2011-2013 нигезендә гамәлгә ашырыла.<br>Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 2 өлешендәге 2 пунктында күрсәтелгән төзелүгә планлаштырыла торган (төзелә торган) күпфатирлы йортлар, шулай ук сатып алынырга тиешле торак Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының 2010 елның 10 июнендәге 64 номерлы карары белән расланган (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) СанПин 2.1.2645-10 «Торак биналарда һәм биналарда яшәү шартларына карата санитар-эпидемиологик таләпләр» нормативларына туры килергә тиеш. |
| 2. | Әзер торак сатып алыначак файдалануга тапшырылган күпфатирлы йортны, төзелеп килүче күпфатирлы йортны конструктив, инженерлык һәм | Төзелеп килүче йортларда түбәндәгеләр булырга тиеш:<br>йорт төзелешенә проект документларына карата шәһәр төзелеше законнары таләпләре нигезендә үткәрелгән экспертизаның уңай бәяләмәсе;<br>түбәндәге материаллардан эшләнгән күтәреп тора торган төзелеш корылмалары:<br>а) стеналары таш корылмалардан (кирпеч, блоклар), эре тимер-бетон блоклардан, тимер-бетон |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | технологик яктан тәэмин итүгә таләп | панельләрдән, тутырылган монолит тимер-бетон каркастан;<br>б) түшәмнәре җыелма һәм монолит тимер-бетон корылмалардан;<br>в) нигезләре җыелма һәм монолит тимер-бетон һәм таш корылмалардан.<br>Җиңел корыч юка стеналы корылмалардан (ЛСТК), SIP панельләр, металл сэндвич-панельләрдән йортлар төзү һәм торак сатып алу киңәш ителми;<br>тиешле ресурслар белән тәэмин итүче һәм башка оешмалар тарафыннан бирелгән техник шартлар буенча үзәкләштерелгән инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру;<br>фатир эчендә ванна, унитаз, раковина булган санитар төен (аерым яки берләштерелгән);<br>йорт эчендәге инженерлык системалары:<br>а) электр белән тәэмин итү (проект документлары нигезендә көч һәм башка электр җиһазлары белән);<br>б) салкын су белән тәэмин итү;<br>в) су чыгару (канализация);<br>г) газ белән тәэмин итү (проект документлары нигезендә булган очракта), авария-диспетчерлык хезмәте күрсәтү мөмкинлеге булган торак бинаның эчке газ үткәргечендә газ йөреше буенча беренче билгеләнгән тиз бикләвеч клапаны белән блокланган газ белән тәэмин итү сигнализаторларын урнаштыру (проект документлары нигезендә);<br>д) җылыту (үзәкләштерелгән җылылык булмаганда һәм газ булганда коллектив яки шәхси газ казаннары урнаштыру киңәш ителә);<br>е) кайнар су белән тәэмин итү;<br>ж) янгын куркынычсызлыгы (проект документлары нигезендә);<br>з) чүп-чар ташлау (проект документлары нигезендә булган очракта);<br>экономия максатында электр белән тәэмин итүнең урындагы системаларын кулланырга киңәш ителә;<br>файдалануга кабул ителгән һәм билгеләнгән тәртиптә теркәлгән лифтлар (проект документлары нигезендә булган очракта).<br>Лифтларны җиһазландыруда киңәш ителә:<br>а) кресло-коляскада утыручы инвалид һәм аны озатып йөрүче зат файдалану өчен билгеләнгән |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | кабина;<br>б) диспетчер белән элемтә өчен җиһазлар;<br>в) авария очрагында лифт кабинасын яктырту;<br>г) лифт кабинасын вандалларга каршы торырлык итеп эшләнгән диод утлы яктырткычлар белән яктырту;<br>д) вандалларга каршы торырлык лифт кабинасы белән идарә итү панеле;<br>тиешле ресурс белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан файдалануга кабул ителгән һәм электр энергиясен, салкын суны, кайнар суны исәпкә алу буенча гомумйорт (күмәк) приборлары классларына билгеләнгән таләпләргә туры килгән үлчәүләрнең (билгеләнгән очракларда үзәкләштерелгән җылылык белән тәэмин иткәндә) дәүләт реестрына кертелгән чаралары;<br>җиңел алып ташлана торган тәрәзә блоклары;<br>йортның катларында баскыч мәйданчыкларын вандалларга каршы торырлык итеп башкарылган диод чыганаклы яктырткычлар, хәрәкәт датчиклары белән яктырту;<br>йорт подъездларына кергәндә вандалларга каршы торырлык итеп эшләнгән диод яктылык чыганагы булган яктырткычлар һәм ут датчиклары белән яктырту, керү ишеге өстендәге козыреклар, тоткычлар һәм автомат рәвештә ишекне ябу җайланмасы булган җылытылган ишек блоклары;<br>йортның подвалына (техник идән) кергәндә йозаклы, тоткычлы һәм автомат рәвештә ишекне ябу җайланмасы булган металл ишек блоклары;<br>йортның бөтен периметры буенча урнаштырылган һәм фундаментка су җибәрмәү мөмкинлеге бирә торган армацияләнгән бетоннан, асфальттан отмостка ясау;<br>су агып төшү өчен махсус куелган торба;<br>йорт яны территориясен төзекләндерү, шул исәптән каты катлам булу, яшелләндерелгән гомуми кулланылыштагы мәйданчыклар, шул исәптән уен комплексы булган балалар уен мәйданчыгы<br>(проект документлары нигезендә) |
| 3. | Функциональ җиһазлануга һәм биналарны бизәүгә | Гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү өчен төзелгән һәм сатып алынган торак биналар йортның подвал, цоколь, техник бүлмәдән, |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | таләпләр | чарлактан кала теләсә кайсы катларында урнашырга һәм анда түбәндәгеләр булырга тиеш:<br>тиешле инженерлык системаларына тоташтырылган йорт эчендәге фатир эче түбәндәге инженерлык челтәрләре белән җиһазландырылган (ким дигәндә):<br>а) саклый торган өзү җайланмалы электр щиты булган электр белән тәэмин итү;<br>б) салкын су белән тәэмин итү;<br>в) кайнар су белән тәэмин итү (үзәкләштерелгән яки автономияле);<br>в) су чыгару (канализация);<br>д) җылыту (үзәкләштерелгән яки автономияле);<br>е) вентиляция;<br>ж) газ белән тәэмин итү (проект документлары нигезендә булган очракта);<br>з) тиешле ресурс белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан эксплуатациягә кабул ителгән һәм электр энергиясен, салкын суны, кайнар суны, табигый газны шәхси исәпкә алу приборлары классларына билгеләнгән таләпләргә туры килә торган үлчәүләрнең дәүләт реестрына кертелгән үлчәү чаралары (билгеләнгән очракларда) (проект документлары нигезендә);<br>эшләнеп беткән чиста бизәкләү эшләре, шул исәптән:<br>а) йозагы, тоткалары һәм ишектәге карау өчен тишеге булган җылытылган керү ишеге;<br>б) йөзлекләре һәм тоткалары булган бүлмә ишекләре;<br>в) йортның энергия нәтиҗәлелеге классына яраклаштырылган, (ике позициядә ачыла торган (фрамуга, форточка) һәм тәрәзә төбе булган энергия нәтиҗәлелеге класслы пыяла пакетлы җиңел алып ташлана торган тәрәзә блоклары;<br>г) вентиляция рәшәткәләре;<br>д) фатирның барлык бүлмәләрендә түшәмдәге яктырту приборлары өчен асылмалы элгечләр;<br>е) фатир эчендә тиешле инженерлык челтәрләренә урнаштырылган һәм тоташтырылган:<br>шалтырату сигнализациясе (проект документлары нигезендә);<br>су җайланмасы һәм сифоны булган юу җиһазы;<br>су җайланмасы һәм сифоны булган юынгыч;<br>утыргычы һәм су агызу багы булган унитаз; |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | су җайланмасы һәм сифоны, җир белән тоташтыру чыбыгы булган ванна;<br>бер, ике клавишлы электр сүндергечләр;<br>электр роозеткалары;<br>фатирның барлык бүлмәләрендә чыгып торган электр үткәргечләр һәм патроннар;<br>газ яки электр плитәсе (проект карары нигезендә);<br>җылы көйләгечләре булган җылылык радиаторлары (проект документлары нигезендә технологик мөмкинлек булганда), автоном җылылык һәм кайнар су белән тәэмин итү вакытында ике контурлы казан;<br>ж) ванна бүлмәсе, бәдрәф (берләштерелгән санитар бүлмәсе), әйберләр саклау бүлмәсе, балконда (лоджия) идән керамик плитка, калган бүлмәләрдә идән – тузу чыдамлыгы 22 класслы һәм югарырак булган ламинат яки күбекле нигездәге линолеум;<br>г) ванна бүлмәсе, бәдрәф (берләштерелгән санузел), әйберләр саклау бүлмәсе, ризык әзерләү бүлмәләрендә (ризык әзерләү бүлмәләрендә эш өслегенә тиеп торучы стенаның (стеналарның) һәм ванна бүлмәсенең ваннага һәм юынгычка тиеп торган стенаның керамик плитка белән капланырга тиешле өлешеннән тыш) стенаны сулы эмульсия яки шундый буяу белән буяу; калган бүлмәләрдә стеналарга обой ябыштыру;<br>д) фатирның барлык бүлмәләрендә түшәмне сулы эмульсия яки башка шундый буяу белән буяу яисә, түшәмне металл яисә пластик профильгә беркетелгән эретеп ябыштырылган винил пленка (ПВХ) яки җөйсез тукымадан эшләү (тарттырылган түшәмнәр) |
| 4. | Материалларга, эшләнмәләргә һәм җиһазларга таләпләр | Күпфатирлы йортны төзү проекты буенча заманча сертификацияләнгән төзелеш һәм бизәү материаллары, эшләнмәләр, технологик һәм инженерлык җиһазларын куллану тәкъдим ителә.<br>Төзелеш торакның проект документлары таләпләренә туры килүен тәэмин итүче материаллар һәм җиһазлар кулланып башкарылырга тиеш.<br>Башкарыла торган эшләр һәм кулланыла торган төзелеш материаллары, гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү максатларында муниципаль контракт нигезендә сатып алына торган торак йорт төзелеше барышында, шулай ук мондый эшләрнең нәтиҗәләре техник регламентларның |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | таләпләренә, энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеше таләпләренә туры килергә тиеш. |
| 5. | Йортның энергия нәтиҗәлелегенә таләп | Россия Федерациясе төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыгының 2016 елның 6 июнендәге 399/пр боерыгы белән расланган энергетика нәтиҗәлелеге классын билгеләү кагыйдәләре буенча «B» классыннан ким булмаган классны күздә тотарга.<br>Йортның энергия нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән түбәндәге чараларны күздә тотарга киңәш ителә:<br>фатирлардагы һәм гомуми файдаланудагы биналарда тәрәзә блокларына югарыда күрсәтелгән өстәмә таләпләр кую;<br>гомуми кулланылыштагы биналарда, баскыч мәйданчыкларында, подъездларга керү юлында хәрәкәт һәм яктылык датчиклары булган диод утлы яктырткычлар урнаштыру;<br>йорт яны территориясен диод утлы һәм яктылык датчиклары кулланып яктырту;<br>подвал (цоколь) һәм чорма түшәмнәренең җылылык изоляциясен булдыру (проект документлары нигезендә);<br>проект документларында каралган кайнар су, салкын су, электр энергиясе, газ һәм башка исәпләү приборларын кую;<br>җылы көйләгече булган радиаторлар урнаштыру (проект документлары нигезендә технологик мөмкинлек булганда);<br>йорт подъездларына керү ишекләрен җылытылган һәм автомат рәвештә ябыла торган җайланма белән җиһазландыру;<br>йорт подъездларына керү тамбурларын стеналарын җылытып урнаштыру, автомат рәвештә ябыла торган җайланмалы, җылытылган тамбур ишекләре (керә һәм үтә торган) урнаштыру.<br>Россия Федерациясе төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыгының 2016 елның 6 июнендәге 399/пр номерлы боерыгы белән расланган күпфатирлы йортларның энергетика нәтиҗәлелеге классларын билгеләү кагыйдәләренең III бүлеге |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | нигезендә, йорт фасадында йортның энергетика нәтиҗәлелеге классы күрсәткече булуны тәэмин итү |
| 6. | Йорттан файдалану документларына таләпләр | Җитештерүче предприятиеләрнең механик, электр, санитар-техник һәм башка төрләргә, шул исәптән лифт җиһазларына, энергетика ресурсларын куллануны исәпкә алу приборларына (гомумйорт (күмәк) һәм шәхси) һәм энергетика ресурсларын бирү белән идарә итү төеннәренә һәм башкаларга карата паспортлары һәм инструкцияләре булу, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491нче номерлы карары белән расланган күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту Кагыйдәләренең 24 һәм 26 пунктларында каралган биналардан куркынычсыз файдалануга таләпләр һәм СП 255.1325800 «Биналар һәм корылмалар. Файдалану кагыйдәләре. Гомуми нигезләмәләр»гә (проект документлары нигезендә) яраклаштырып эшләнгән күпфатирлы йорттан файдалану Инструкциясе кертелгән тиешле документлар (документ күчермәләре) булу.<br>Фатир эчендәге инженерлык җиһазларыннан файдалану буенча инструкцияләр булу. Фатир эчендәге инженерлык җиһазларыннан файдалану буенча инструкцияләр җыелмасы заказ бирүчегә тапшырылырга тиеш. |